ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АКТАНЫШ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ КИРОВ АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ БАШКАРМА
КОМИТЕТЫ

423747, Киров авылы,
Киров урамы,52 йорт.
тел.факс.: (85552) 3-44-47
e-mail: kirov.sp@yandex.ru

ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
КИРОВСКОГО СЕЛЬСКОГО
ПОСЕЛЕНИЯ АКТАНЫШСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

423747, пос. совхоз им. Кирова,
ул. Кирова, дом 52.
тел.факс.: (85552) 3-44-47
e-mail: kirov.sp@yandex.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

**«17» июнь 2025 ел** **№ 12**

**Актаныш муниципаль районы Киров авыл җирлеге башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы Киров авыл җирлеге хезмәткәрләренең эчке хезмәт тәртибе кагыйдәләрен раслау турында» 2023 елның 16 февралендәге 6 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында**

«Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2021 елның 30 апрелендәге 116-ФЗ номерлы, «Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2022 елның 05 декабрендәге 498-ФЗ номерлы, «Россия Федерациясе дәүләт хезмәте системасы һәм Россия Федерациясенең аерым закон актлары турында «Федераль законның 12 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» 2023 елның 12 декабрендәге 594-ФЗ номерлы, «Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» Федераль законның 16 статьясына үзгәреш кертү хакында» 2024 елның 30 сентябрендәге 338-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Актаныш районы прокуроры вазыйфаларын башкаручының 2025 елның 03 июнендәге 02-08-02-2025/Прдп 181-25-20920005 номерлы протестын карап, Актаныш муниципаль районы _Киров авыл җирлеге Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. Актаныш муниципаль районы Киров авыл җирлеге Башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы Киров авыл башкарма комитеты хезмәткәрләренең эчке хезмәт тәртибе Кагыйдәләрен раслау турында» 2023 елның 16 февралендәге 6 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

**1.1. 2.4 пунктта:**

**а) 2 пунктчаны** түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2) «Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» 2007 елның 02 мартындагы 25-ФЗ номерлы Федераль законның 15_2 статьясында каралган анкета;

**б) 4 пунктчаны** түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

4) хезмәт кенәгәсен һәм (яисә) хезмәт эшчәнлеге турында законнарда билгеләнгән тәртиптә рәсмиләштерелгән белешмәләрне, хезмәт шартнамәсе (контракты) беренче тапкыр төзелгән очраклардан тыш; (Федераль законның 31.07.2020 № 268-ФЗ редакциясендә)

**в) 5 пунктчаны** түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

5) мәгариф һәм квалификация турында документ;»

**д) 14** абзацта «белешмәләр» сүзләреннән соң «(анкетадагы белешмәләрдән тыш)» сүзләрен өстәргә,

**1.2 2.14 пунктта :**

**а) 4 абзацны** үз көчен югалткан дип танырга.

**б) түбәндәге эчтәлекле** **абзац** өстәргә:

«- муниципаль хезмәткәрләргә чит ил агенты статусын алу

**4.2 пунктына** түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«- яллаучы вәкиленә (эш бирүчегә) «Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» 2007 елның 02 мартындагы 25-ФЗ номерлы Федераль законның 15.2 статьясында каралган анкетада булган белешмәләрнең мәгълүм үзгәрешләре турында язма формада хәбәр итәргә, моңа яллаучының (эш бирүченең) вәкиле карары буенча үзгәргән белешмәләр керми (алга таба - анкетадагы белешмәләр).

2. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Башкарма комитет җитәкчесе Даутов Д.Н.